ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**КАРАР**

«21» апреле 2017 ел № 82

Зур Ключи авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы Когогина В. Г. мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 өлешенең 38 пунктын, 3 өлешен исәпкә алып, Зур Ключи авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Зур Ключи авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип тану:
- 2014 елның 22 октябрендәге 171 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карары;;
- 2015 елның 17 августындагы 222 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында Нигезләмәне раслау хакында «Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлеге Советының 2014 елның 22 октябрендәге 171 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карары;

- Зур Ключи авыл җирлеге Советының «Зур Ключи авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында Нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 22 октябрендәге 171 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «гы 2016 елның 15 апрелендәге 32 номерлы карары (Большие Ключи авыл җирлеге Советының 2015 елның 17 августындагы 222 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зур Ключи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Зур Ключи авылы, Волостнов ур., 16а йорт (авыл җирлеге администрациясе бинасы), Зур Ключи авылы, Волостнов ур., 21 йорт (кибет бинасы), һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарны 2017 елның 24 апреленә кадәр Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрергә.

**Зур Ключи авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **В.Г. Когогина**